

9 февраль конне Ләмберәнен «Алмаз» мәдәният сараенда vткән «Уйна, гармун!»да Мордовия Респуб-ликасынын 11 муниципаль районыннан - Ардатово, Атяшево, Большие Березники, Большое Игнатово, Дубенки, Ичалково, Кочкурово, Лямбирь, Ромоданово, Рузаевка, Чамзинка һәм Саранск шәһәреннән vзэшчән артистлар vз осталыкларын кvрсәттеләр. «Уйна, гармун!» фестиваль-конкурсынын сайлап алу турынын икенчесе vтте.      Зона концертында торле яшьтәге vзэшчән артистларыбыз инструменталь койләр, халык жырлары, такмаклар янгыраттылар. 2025 елда фестиваль-конкурс Ватанны саклаучылар елына һәм Россиядә Боек Жинvнен 80 еллыгына һәм Мордовия Республикасында Тарихи хәтер елына багышланган иде.
Конкурс программасына патриотик жырлар һәм сугыш еллары жырлары кертелгән. Жюри илледән артык конкурс номерын карады. Сайлап алу туры даими катнашучылардан тыш яна башкаручыларны һәм яна ижат коллективларын кvрсәтте.



Һәрвакыттагыча «Уйна, гармун!» Рес-публика халык ижаты фестиваль-конкур-сынын Гала-концерты Республика мәдәният сараенда узачак.
Рузаевка районындагы Татар Пешләсендә милли мәдәниятыбызны саклыйлар; мәдәният олкәсендә торле-торле чаралар vткәреп торалар. Шулай Рузаевка районы Татар Пешлә БИТ21 китапханәсендә Ләйлә Саляева житәкчелегендә «Традиция жепләре» дигән Арт студиясендә катнашучылар татар хатын - кызлары очен чалгы бизәкләре белән чулпы ясаганнар.
Татар хатын-кызларынын толымнарына беркетелгән тасма ярдәмендә vрел-гән бу бизәк кенә тvгел, ә нәфислек һәм матурлык символы да булган. Безнен әбиләребез шулай vреп йоргәнен мин дә хәтерлим. Чулпыларнын формасы, материалы һәм техникасы, декоратив-сәнгати бизәлеше һәм киеп йорv ысуллары торле булган. Әлеге эш борынгы кvнекмәләрне саклап кына калмый, бәлки, vсеп килvче буынга татар традицияләренен матурлыгын ачарга момкинлек биреп, халык ижаты белән кызыксынуны янартырга ярдәм итә.

Н.ХӘЛИЛ